МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

Татарстан Республикасының экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 10.09.2012 № 351-п приказы белән расланган, Татарстан Республикасында урындагы җир астын куллану хокукына ия булу өчен уздырылган ачык сатуларны үткәрүнең әзерлек тәртибе һәм аларны үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәртүләр кертү хакында

Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрлыгының норматив актларын канунчылыкка нигезләп тәртипкә китерү һәм Татарстан Республикасында урындагы җир астын куллану хокукы турында ачык сатуларны үткәрүнең эффективлыгын арттыру максатыннан боерам:

1. Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан расланган 10.09.2012 № 351-п (Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрлыгы боерыклары буенча кертелгән үзгәрешләр белән 23.11.2012 № 494-п, 24.10.2013 № 625-п, 21.01.2014 № 32-п) Татарстан Республикасында урындагы җир астын куллану хокукына ия булу өчен уздырылган ачык сатуларны үткәрү нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2 пунктында “таралган җир асты казылмалары булган җирләрне” сүзтезмәсен бетерергә;

2.1 пунктын түбәндәгеләрне исәптә тотып үзгәртергә:

“2.1. Ачык сатуларга каралган тәртип буенча Татарстан Республикасы буенча урындагы җир асты исемлегенә кертелгән (алга таба: Исемлек) җир аслары чыгарыла.”;

4.7. пунктындагы “03.08.2011 № 650 “Россия Федерациясе хөкүмәте карары буенча (28 сентябрь 2010 е. № 767) кертелгән үзгәртүләр хакында” сүзләрен түбәндәгечә алыштырырга: “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә ачык сатулар үткәрү хакында һәм Россия Федерациясе хөкүмәтенең кайсыбер актларына үзгәртүләр кертү турындагы мәгълүматларны элеп бару өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтын билгеләү хакында (10.09.2012 № 909)”

түбәндәге эчтәлектәге 5.5 пункты белән тулыландырырга:

“5.5. Ачык сатуларда катнашучылар исеменнән аларның ихтыяҗларын Россия Федерациясе канунчылыгына нигезләп, физик һәм юридик затлар чыгыш ясый алырга хокуклы.

“6.1. Ачык сатуларда катнашу өчен Ачык сатуларда катнашырга дәгъва итүче (алга таба – гариза бирүче) җир асты фонды белән идарә итүче фондка Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән гариза һәм түбәндәге документларны тапшыра:

гариза бирүченең оештыручы документлары күчерелмәләре (әгәр дә гариза бирүче юридик зат булса);

гомум дәүләт реестрыннан (шәхси эшмәкәрләрне теркәүче гомум дәүләт реестрыннан) юридик затларны теркәүче өземтә;

салым түләү органында теркәлүне раслаучы, салым түләүченең идентификацион номеры күрсәтелгән таныклык күчерелмәсе;

салым түләү органыннан гариза бирүченең салым һәм җыем түләү буенча бурычлары булмавын дәлилләүче белешмә;

гариза бирүченең һәм җир асты биләмәләре белән куллану эшләренә җәлеп ителүчеләрнең лицензия күчерелмәләре (булган хәлдә);

гариза бирүченең соңгы хисап көненә булган салым органы кабул итүе хакында билгеләмәле бухгалтер балансы күчерелмәсе;

банк оешмаларыннан гариза бирүченең гариза биргәнгә тиклем бер ай дәвамында хисаплары әйләнешен тасвирлаучы белешмә;

заем һәм кредит (булган хәлдә) килешүнамәләренең күчерелмәләре;

подряд килешүнамәләренең күчерелмәләре (булган хәлдә);

кулланылучы технологияләр хакында белешмә; җирне чоку, тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник җиһазларның исемлеге, әлеге технологияләр һәм җиһазларның гариза бирүче яки эшкә җәлеп ителгән подрядчикларныкы булуы хакында белешмә;

гариза бирүченең яки подрядчикларның штат җәдвалы;

эшне башкарачак квалификацияле белгечләрнең диплом күчерелмәләре;

Документ күчерелмәләре билгеләнгән тәртип буенча расланган килеш яки документларның төп нөсхәсе белән берлектә күрсәтелергә тиеш.”;

6.8 пунктының 3 нче матдәсендә “шулай ук җир асты биләмәләрен куллану белән бәйле башкарылачак эшләрне үтәү өчен кирәкле булган финанс чыгымнарны” сүзтезмәсен алып ташларга;

7.0. пунктының беренче абзацында “лицензия проектлары һәм” сүзтезмәсен “проектының” сүзенә алыштырырга;

8 нче бүлекне түбәндәгеләрне исәптә тотып үзгәртергә:

8. Ачык сатулар нәтиҗәләре буенча карарларны кабул итү

8.1. Ачык сатулар нәтиҗәләре буенча Ачык сатулар комиссиясе тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

- Ачык сатулар нәтиҗәләрен кабул итү турында һәм әлеге Ачык сатуларның җиңүчеләренә билгеләнгән өлешчә җир астын куллану рөхсәтен раслау турында;

- әлеге Нигезләмәнең 7.5. нче пунктында билгеләнгән сәбәпләр аркасында Ачык сатулар узмаган дип санарга;

- Ачык сатуларны уздыруда кануннарның бозылганлыгы табылу сәбәпле (шул исәптән Ачык сатуларны алып бару тәртибе бозылган хәлдә дә) Ачык сатуларны туктатырга.

8.2. Ачык сатулар нәтиҗәләре алар үткәннән соң 30 календарь көн дәвамында расланырга тиеш.

8.3. Министрлык үз компетенциясендә булган Ачык сатуларның үткәрү шартларын әзерләү, аларны үткәрү һәм Ачык сатулар нәтиҗәсе буенча җир асты белән куллану рөхсәтен раслау белән бәйле вәкаләтләрне башкара, Министрлыкның рәсми сайтында нәтиҗәләр игълан ителгәннән соң 30 календарь көн дәвамында әлеге мәгълүматны куюны тәэмин итә.

8.4. Ачык сатулар нәтиҗәләре буенча җиңүчегә бер тапкырлы салым һәм лицензия бирү өчен дәүләт җыемы түләгәннән соң, җир асты турындагы канунчылыкта каралган тәртип буенча корылган лицензия тапшырыла.

8.5. Ачык сатуларның җиңүчесенә лицензия бирү өчен аның тарафыннан башка өстәмә документлар тапшырылуы соралмый.

8.6. Җир астын куллану рөхсәтен бирүче лицензия Ачык сатулар булмаган дип табылган хәлдә, Ачык сатуларның нәтиҗәләре буенча лицензия бирелү турындагы протоколга кул куелу көненнән соң 10 календарь көн алдарак яки әлеге протокол нәтиҗәләре Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш булса, урнаштырылу көненнән соң 10 календарь көннән алдарак та лицензия тапшырыла алмый.

Кушымтада:

Урындагы җир асты өлешләре белән куллану рөхсәте алу максаты белән оештырылган Ачык сатуларны уздыру шартлары турындагы типик тәртипнең 1.3 нче пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

5 нче бүлектә "Урындагы җир асты белән кулланырга рөхсәт алу өчен уздырылган Ачык сатуларны үткәрүнең типик тәртибе һәм үткәрү шартлары Лицензион килешүгә кертелә (җир асты белән куллану турындагы лицензиягә кушымта № 1) һәм ул җир асты белән куллануга рөхсәт барлыгын раслаучы лицензиянең аерылгысыз өлешен тәшкил итә.";

Урындагы җир асты белән кулланырга рөхсәт алу өчен уздырылган Ачык сатуларны үткәрүнең типик тәртибенең 2 нче бүлеген түбәндәге эчтәлекле 2.3. пункты белән тулыландырырга:

"2.3. Ачык сатуларда катнашучылар исеменнән аларның ихтыяҗларын Россия Федерациясе канунчылыгына нигезләнеп, Ачык сатуларда катнашучылар исеменнән чыгыш ясый алырга хокуклы физик һәм юридик затлар алып бара ала.";

Урындагы җир асты өлешләре белән куллану рөхсәте алу максаты белән оештырылган Ачык сатуларны уздыру шартлары турындагы типик тәртипләрнең 3 нче бүлеген түбәндәге редакциядә тасвирларга:

"3. ҖИР АСТЫ ӨЛЕШЕ ХАКЫНДА ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТ

3.1. кулланылышка бирелүче җир асты өлеше (яки чыганак) Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрлыгының боерыгы тарафыннан (_________№________) Татарстан Республикасында урынлы җир асты биләмәсе исемлегенә кертелгән.

3.2.______________________________________________________________________

(урындагы җир асты биләмәсенең атамасы)

Татарстан Республикасының

_________________________________________________________________________

муниципаль районында ____________________________________ урнашкан.

(географик урыны билгеләнә)

3.3. Тау отводының тәфсилләнгән чикләрен билгеләүче документларны регистрацияләү көненнән алып, геологик өйрәнүләр һәм тау отводының җир асты өлешләренә геологик отвод дәрәҗәсе бирелә.

Планда кулланылуга тапшырылган җир асты контурлары түбәндәге географик координатлары булган почмак нокталар белән чикләнә (WGS-84):

| Җир асты биләмәләренең почмак ноктасы номеры | Төньяк киңлек | | | Көнчыгыш озынлык | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Градуслар | Минутлар | Секундлар | Градуслар | Минутлар | Секундлар |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Җир асты биләмәләренең мәйданы ________ га.

3.4. Тау отводларының чикләре

________________________________________________________________

(таралган җир асты казылмасының атамасы) запаслары расланганнан соң, сәнәгать категорияләрендә, техник проектны булдыруда, аны куллану өчен дәүләт экспертизасының уңай карары һәм кирәк булган башка төр яраштыруларда билгеләнә.

3.5. Җир асты территориясендә федераль, региональ һәм урындагы табигатьне саклау органнары тарафыннан исәптә тотылган урыннар юк.

3.6. Җирнең бер өлеше җир асты белән кулланучыга түбәндәге максатлар белән бирелә:

(җир астын белән куллану максаты һәм таралган җир асты казылмасының атамасы)

югарыда күрсәтелгән эшләрнең проектлары кабул ителгәннән соң, җир асты территориясендә эшләр Россия Федерациясенең канунчылыгы билгеләгән тәртиптә башкарыла.”;

пункт 5.2.2 Урындагы җир асты белән кулланырга рөхсәт алу өчен уздырылган Ачык сатуларны үткәрүнең типик тәртибе һәм үткәрү шартларын түбәндәге редакциядә тасвирларга:

“5.2.2. Җир асты казылмаларын рациональ куллану һәм тирә-як табигатьне саклау максатлары белән җир асты белән кулланучы түбәндәге кагыйдәләрне үтәргә тиеш:

а) җир астын куллану һәм саклау кануннарын, кагыйдәләрен һәм нормаларын үтәргә;

б) җир астыннан мөмкин кадәр күбрәк җир асты казылмаларын чыгарырга, аларны казып алган чагында җир астын пычратмаска, җир асты казылмаларының сыйфатын киметә яки аларны эшкәртүне катлауландыра торган гамәлләрдән лицензияләнгән җирне сакларга, лицензияләнгән җирнең сәнәгати кыйммәтен сакларга;

в) җир асты казылмаларын табу яки җир астында калдыру хакында маркшейдер эшләре алып бару һәм җир астын саклау кагыйдәләрендә тасвирланганча, маркшейдер төшерүенә мөрәҗәгать итеп, төгәл исәп алып барырга;

г) җир астын куллану белән бәйле рәвештә тирә-якка зыян салуны бетерергә яки мөмкин кадәр азайтырга;

д) җир астын рациональ куллану һәм саклау, тирә-якны саклау, сакчыл эш алып бару кагыйдәләрен үтәргә;

е) тау отводы чыганагының чикләреннән чыкмыйча җир асты казылмаларын эзләү эшләрен алып барырга;

ж) җир астын кулланучы проект документларында расланган нормативлардан артып киткән җир асты казылмаларын югалту турында Татарстан Республикасының экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән үз вакытында килешү төзергә тиеш;

з) проект документациясенә расланган нормативлардан артмаган җир асты казылмаларын югалтулары җир астын кулланучы тарафыннан ел саен расланырга тиеш;

и) җир астын кулланучы чыганакны алдан расланган проект документлары буенча гына төзергә тиеш;

к) барлык төр җир асты белән куллану эшләре алып барган чакта да геологик һәм маркшейдер документларын алып барырга;

л) җир астын куллану белән бәйле эшләргә рөхсәт бирүче документлар (җир асты белән куллануга рөхсәт бирүче лицензияләр һәм аларның кушымталары, агымдагы вакытта тау эшләрен алып баруын раслаган план буенча төзелгән тау саклау акты һәм топографик планы, җир өлешен сәнәгать җиренә күчерү турындагы карар (җир асты белән җир өлеше урыннарында куллану очраклары өчен), Балыкчылык буенча Федераль агентлыкның урындагы органыннан рөхсәт (җир асты өлешләре су объектларында һ.б. урнашкан очракларда) һәм аларны бу эшләрне контрольдә тотучы органнарга тапшырырга;

м) тау эшләрен алып баруның техник проектлары, планнары һәм схемаларының тәртибен үтәргә, нормативтан тыш булган югалтуларны булдырмау, җир асты казылмаларын пычратмаска, аларны аерым-аерым эшкәртмәскә;

н) чыганакны эшкәртү процессында запасларны үз вакытында чыгару, җир катламнары һәм тау токымнарын аерым алып куярга;

о) җир асты белән куллану процессында сирәк палеонтологик, археологик һәм башка объектлар табылган хәлдә Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрлыгына хәбәр итәргә;

п) контроль алып баручы органнарның барлык боерыклары да үтәлергә тиеш.

Аерым бүлемтекләрдә җир астын куллану очракларында 5.2.2 пунктының а-п пунктларына өстәмә рәвештә җир астын кулланучыга түбәндәге кагыйдәләрне үтәү йөкләнә:

р) җир асты казылмаларын махсус категориясе булган җирләрдә генә казырга (“сәнәгать җирләре”);

с) җир асты белән куллану вакытында зыян килгән җир өлешләрен һәм башка табигый объектларны киләчәктә кулланырга мөмкин итеп төзекләндерү;

т) лицензия вакыты чыгу белән, шулай ук канунчылыкта каралган төрле сәбәпләр аркасында җир асты белән кулланырга рөхсәт ителгән вакыт алданрак бетсә җирләрне алдагы хуҗасына кайтару;

у) җир асты казылмалары булган урыннарда үзлектән башкарылачак төзү эшләре хакында алдан кисәтү, башка максатлардан әлеге җирләрне куллану тәртибен сакларга.

Су объектларында булган җир астын кулланган очракта 5.2.2 пунктының а-п өлешләренә өстәмә рәвештә җир асты белән куллануның түбәндәге кагыйдәләре дә каралган:

р) ел саен, навигацион вакыт башланганчы, эшләрне башкаруга Балыкчылык буенча Федераль агентлыкның урындагы органыннан махсус ризалык (килешенү) алырга;

с) җир астын кулланучы тарафыннан таралган җир асты казылмаларын табуга рөхсәт бирелгән лицензия нигезендә елга һәм диңгез судноларын «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмати системасына ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS спутник навигаторлары ярдәмендә тоташтырырга;

т) кабул ителгән тәртип буенча урнаштырылган таксаны һәм су биоресурсларына китерелгән зыянны санау өчен кабул ителгән методиканы үтәү, канунчылык буенча кабул ителгән тәртиптә аларны түләү.”

Урындагы җир асты белән кулланырга рөхсәт алу өчен уздырылган Ачык сатуларны үткәрүнең типик тәртибенең 5.2.3 нче пунктын түбәндәге эчтәлекле “н” һәм “о” матдәләре белән тулыландырырга:

“н) тирә-якны пычрату белән бәйле барлык төр аварияләр хакында Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрлыгына һәм башка вәкаләтләре булган органнарга оператив рәвештә хәбәр итәргә;

о) кулланылырга бирелгән җир асты чикләрендә урнашкан тау эшкәртү җиһазлары, скважиналар һәм башка төр җиһазларның куркынычсызлыгын тәэмин итәргә.”;

Урындагы җир асты белән кулланырга рөхсәт алу өчен уздырылган Ачык сатуларны үткәрүнең типик тәртибенең 5.10 нчы пунктына түбәндәге төзәтмәләрне кертергә:

“5.10. Җир асты һәм аларны куллану турында мәгълүмат.

5.10.1. Башка федераль законнар белән каралган һәм расланган тәртипләр буенча җир асты турындагы геологик мәгълүмат Россия Федерациясенең махсус дәүләт органнарына, Татарстан Республикасының җир асты фонды белән идарә итүче органга һәм әлеге органнар кул астында эшләүче оешмаларга тапшырылырга тиеш.

Әлеге мәгълүматне куллану тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы канунчылыгына таянган хәлдә, Татарстан Республикасының җир асты фонды белән идарә итүче орган тарафыннан урнаштырыла.

5.10.2. Үз хисабына җир асты хакындагы ачыкланган геологик яки башка төр мәгълүматлар җир асты белән кулланучының шәхси мөлкәте санала.
Геологик мәгълүмат җир астын кулланучы тарафыннан киләчәктә бу мәгълүматны саклаячак һәм системалаштырачак Татарстан Республикасының җир асты фонды белән идарә итүче органга билгеләнгән тәртип буенча тапшырылырга тиеш.

5.10.3. Җир асты турында геологик мәгълүмат җир асты турында беренчел геологик мәгълүмат һәм җир асты турында интерпретацияләнгән мәгълүматка бүленә.

Җир асты турында беренчел геологик мәгълүматлар белән җир астын кулланучы идарә итә. Җир астын кулланучы Татарстан Республикасының җир асты фонды белән идарә итүче органга геологик мәгълүматны тапшырганнан соң, 3 ел дәвамында җир астын куллану шартларын билгеләргә хокуклы, шул исәптән, коммерция максатларында да.

Интерпретацияләнгән геологик мәгълүматларга ия булган җир астын кулланучы Татарстан Республикасының җир асты фонды белән идарә итүче органга геологик мәгълүматны тапшырганнан соң, 5 ел дәвамында җир астын ни рәвешле кулланырга икәнлеген үзе карарга хокуклы, шул исәптән коммерция максатларында да.

5.10.4. Закон белән каралган аерым бер очракларда Россия Федерациясенең дәүләт органнары, дәүләт органнары карамагында эшләүче оешмалар җир астын кулланучының рөхсәтеннән башка да җир асты турындагы геологик мәгълүмат белән файдаланырга мөмкин.

Югарыда телгә алынган вакыт үтү белән җир асты белән куллану хокуклары Татарстан Республикасына күчә. Шул ук вакытта җир астын кулланучы тарафыннан үз хисабына җир асты турында табылган геологик мәгълүматлар канунчылык рөхсәт иткән теләсә нинди ысуллар белән кулланылырга мөмкин.

5.10.5. Җир асты турындагы геологик һәм башка төр мәгълүматлар Россия Федерациясенең канунчылыгы тарафыннан расланган башка милек объектлары өчен булган тәртиптә саклана.

5.10.6. Лицензиянең вакыты чыгу белән, шул исәптән вакытыннан алда чыгу белән, җир астын кулланучы Татарстан Республикасының экология һәм табигый байлыклар министрлыгына киләчәктә саклау өчен җир асты кишәрлекләре буенча эшләрне бетерү моментына булган барлык төр геологик, топогеодезик, маркшейдер документларын тапшыра";

Урындагы җир асты өлешләре белән куллану рөхсәте алу максаты белән оештырылган Ачык сатуларны уздыру шартлары турындагы типик тәртипнең 7.9. пунктының 3 нче матдәсендә түбәндәге сүзләрне бетерергә: "шулай ук, җир асты белән куллануда оештырылачак эшләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалата ярдәм белән".

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт регистрациясенә кую өчен Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлүе министрның урынбасары вазифаларын вакытлыча үтәүче Р.Н.Гәйнетдинова контроленә бирелә.

Министр Ф.С. Абдулганиев